**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге составына керүче Андреевка авылында гражданнар җыены карары**

**"20" ноябрь 2025 ел № 2**

**14.00**

**Андреевка авылы,**

**Совет ур., 36 й.**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 һәм 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Андреевка авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Андреевка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Андреевка авылы торак пунктындагы чишмәне төзекләндерү)

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**

**«Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы**

**___________ Л. А. Малахаева**